ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.04.2022 ел Баулы шәһәре №62

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 10 июнендәге 130 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларга өстәмә белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 апрелендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 10 июнендәге 130 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларга өстәмә белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирүнең муниципаль системасы төрле юнәлештәге өстәмә гомуми белем бирү (өстәмә гомуми белем бирү, сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү һәм өстәмә белем бирү) программаларын гамәлгә ашыручы төрле типтагы һәм төрдәге муниципаль мәгариф учреждениеләреннән гыйбарәт.»;

4.4. пунктта «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия белән,» сүзләрен «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү датасы һәм теркәү номеры турында белешмәләр белән» сүзләренә алмаштырырга;

4.8. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Өстәмә гомуми үстерү программаларын тоту һәм алар буенча укыту сроклары белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы балаларга өстәмә белем бирүнең муниципаль учреждениеләре тарафыннан эшләнгән һәм расланган белем бирү программалары белән

билгеләнә. Сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программаларның эчтәлеге белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы учреждение эшләгән һәм расланган белем бирү программасы белән федераль дәүләт таләпләре нигезендә билгеләнә. Спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларының эчтәлеге спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган учреждение эшләгән һәм раслаган тиешле белем бирү программасы белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарның 1 пунктының 4.1., 4.8. пунктчалары нигезләмәләре 2023 елның 1 гыйнварыннан кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.И. Хөснуллина